ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31 01 2025 г. № 80

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, «2025 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2025 елның 23 гыйнварындагы 33 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Түбән Кама шәһәре, Кама Аланы шәһәр тибы поселыгы һәм Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында кабул ителгән килешүләрне исәпкә алып, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2025 елның 1 февраленнән Түбән Кама муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен әлеге карарның 1 нче кушымтасы һәм 2 нче кушымтасы нигезендә 9 165,37 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2024 нче елның 31 нче гыйнварындагы 77 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Г. Парамоновка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов

Кушымта № 1
Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карарына
«31» 01 2025 № 80

2025 нче елның 1 нче февраленә Түбән Кама муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән бәясе исемлеге

| Хезмәтләр исемлеге | Хезмәт бәясе(сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Каберне һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 760,00 |
| 3. Үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка ташу | 680,00 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 7725,37 |
| Барлыгы | 9165,37 |

Кушымта № 2
Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карарына
«31» 01 2025 № 80

2025 нче елның 1 нче февраленә Түбән Кама муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән бәясе исемлеге

| Хезмәтләр исемлеге | Хезмәт бәясе(сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Кәфенлек (мәрхүмнең киеме) | 380,00 |
| 3. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предмет-ларны бирү һәм китерү | 760,00 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 680,00 |
| 5. Кабер казу һәм күмү) | 7345,37 |
| Барлыгы | 9165,37 |